КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

17.11.2023 Казан № 824-П

Татарстан Республикасы Алекссевски муниципаль районында урнашкан «Гурьевка III авылы», безнең эрага кадәр X–XIII гасырлар федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләре һәм махсус файдалану режимынраслау турында

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 12 июлендәге 565 номерлы «Мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы комитеты мәсьәләләре» карары нигезендә боерам:

1. Расларга:

бу боерыкка 1 кушымта нигезендә атарстан Республикасы Алекссевски муниципаль районында урнашкан «Гурьевка III авылы», безнең эрага кадәр X–XIII гасырлар федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясенең чикләрен (бастырылып чыгарылырга тиеш түгел);

бу боерыкка 2 кушымта нигезендә атарстан Республикасы Алекссевски муниципаль районында урнашкан «Гурьевка III авылы», безнең эрага кадәр X–XIII гасырлар федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясеннән махсус файдалану режимын.

2.Мәдәни мирас объектларын исәпкә алу һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге бүлегенә күрсәтелгән төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләре турындагы белешмәләрне Бердәм күчемсез милек дәүләт реестрына һәм Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренең) бердәм дәүләт реестрына кертүне тәэмин итәргә.

3. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Рәис И.Н. Гущин

Татарстан Республикасы
Мәдәни мирас объектларын
саклау комитетының 2023 елның
17 ноябрендәге 824-П
боерыгына 2 кушымта

Татарстан Республикасы Алекссевски муниципаль районында урнашкан «Гурьевка III авылы», безнең эрага кадәр X–XIII гасырлар федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясеннән **махсус файдалану режимы**

Археологик мирас объекты чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның аерым режимы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба - 73-ФЗ номерлы Федераль закон), җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләре, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының бердәм дәүләт реестрына кертелгән археологик мирас объектының (тарих һәм мәдәният ядкарьләренең) сакланышын тәэмин итү шартларында урманнардан файдалану буенча 73-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясында күрсәтелгән җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләрен башкару мөмкинлеген күздә тота.

**1. Рөхсәт ителә:**

мәдәни мирас объектларын саклауның федераль органы биргән рөхсәт (ачык кәгазь) нигезендә археологик мирас объектын өйрәнү эшләрен үткәрү, шул исәптән археологик предметларны эзләү һәм тартып алу максаты булган эшләрне дә кертеп;

73-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясында күрсәтелгән урманнардан һәм археологик мирас объекты территориясе чикләрендә бүтән эшләрдән файдалану буенча эшләр башкару, проектлау, җир, төзелеш, мелиоратив, хуҗалык эшләрен башкару, мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм саклау өлкәсендә вәкаләтле орган белән килештерелгән мәҗбүри бүлекләрне археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү турындагы яисә археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү проектлары яисә археологик мирас объектына үткәрелә торган эшләр йогынтысын бәяләүне кертә торган коткару археологик кыр эшләрен башкару планын күрсәтелгән мәҗбүри эшләрне башкару;

археологик мирас объектын музейлаштыру чараларын үткәрү;

законнар нигезендә гражданнарның археологик мирас объектына керүен оештыру;

үләннәрен чаптыру, территорияне коры-сарыдан, үзләре тишелеп үскән агачларны һәм куакларны чистарту.

**2. Тыела:**

73-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясында күрсәтелгән, археологик мирас объекты территориясе чикләрендә урманнардан һәм башка эшләрдән файдалану буенча, реестрга кертелгән, мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм саклау өлкәсендә вәкаләтле орган белән килештерелгән мәҗбүри бүлекләрне археологик мирас объектының

сакланышын тәэмин итү турында яисә археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү проектлары йә археологик мирас объектына үткәрелә торган эшләр йогынтысын бәяләүне кертә торган коткару археологик кыр эшләре планын уздыру буенча эшләр башкару, проект, җир, төзелеш, мелиоратив, хуҗалык эшләрен башкару;

грунт, каты һәм һәм башка, шул исәптән төзелеш калдыкларын туплау;

грунт һәм башка токымнарны алу;

билгеләнгән урыннардан тыш чүп-чар калдыкларны ташлау.